ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

19.11.2020 г. Заинск № 521

**«Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районында спорт резервын әзерли торган физкультура спорт оешмаларында эшләүче хезмәткәрләр - яшь белгечләргә акчалата түләүләр билгеләү турында» 2020 елның 27 мартындагы 128 номерлы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү хакында”**

«Татарстан Республикасының спорт резервын әзерләүче физкультура спорт оешмалары хезмәткәрләренә - яшь белгечләренә акчалата түләүләр билгеләү турында» 2019 елның 31 октябрендәге 979 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарын үтәү йөзеннән, Зәй муниципаль районы Уставының 45 статьясына таянып,Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты

**карар бирә:**

1. «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районында спорт резервын әзерли торган физкультура спорт оешмаларында эшләүче хезмәткәрләр - яшь белгечләргә акчалата түләүләр билгеләү турында» 2020 елның 27 мартындагы 128 номерлы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты карарының 1 пунктына үзгәреш кертергә, аны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы башкара торган Татарстан Республикасы спорт резервын әзерләүче дәүләт физкультура спорт оешмаларында, Татарстан Республикасының спорт резервын әзерләүче муниципаль физкультура спорт оешмаларында эшләүче хезмәткәрләр - яшь белгечләргә түбәндәге акчалата түләүләрне билгеләргә:

ай саен эшләнгән вакытка пропорциональ рәвештә 1 111 сум күләмендә, әмма аена 1 111 сумнан да артык түгел, стимуллаштыру өстәмә акчасы;

хуҗалыкны көйләүгә бер тапкыр бирелә торган 20 000 сум күләмендә

акчалата түләү».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2020 елның 1 сентябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары А.В. Чапков йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе**
**вазыйфаларын башкаручы** **М.И.Захарова**

Юрист
И.З. Әшрәпов
(85558) 35367